**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422723 Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Алан-Бексер, ул.Центральная, д.19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур.,19 йорт

Тел./факс: +7(84365) 63-951, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**18.03.2025 ел** **№ 129**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендә № 194 кабул ителгән “Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Прокуратурасы протестына нигезләнеп, Россия Федерациясе Салым кодексы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 18.11.2019 № 194 карарына (Советның 19.05.2020 № 217, 16.11.2022 № 64, 29.11.2022 № 66, 27.12.2023 № 93 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның 1 нче пунктчасында 3 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләре, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләре һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләре;»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсенә ярашлы рәвештә законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина